ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е                                        К А Р А Р

2019 елның «27» июне                                        №841

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомствосындагы Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре һәм аерым типовой булмаган оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 14 августындагы 665 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы карамагындагы аерым типлаштырылмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 21 июнендәге 505 нче карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомствосындагы «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре һәм аерым типовой булмаган оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 27 августындагы 1252 номерлы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. V бүлектә:

6нчы абзацта 2.4нче пункттагы «26,5» цифрны «41,0» дип үзгәртергә;

6нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6нчы таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | - | 41,0 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | Беренче-дүртенче | 41,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының профессиональ квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0»; |

алтынчы абзацта 4.4 пунктта «26,5» санын «41,0» санына үзгәртергә;
11нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11нче таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Вазифа атамасы | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Ярдәмче составның вазыйфаи техник башкаручылары һәм артистлары» һөнәри квалификация төркеме | Барлык вазифалар | 41,0 |
| “Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюмерная мөдире | 49,0 |
| | Түгәрәк, клуб җитәкчесе, мәдәни оештыручы | 61,0 |

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Вазифа атамасы | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| “Әйдәп баручы звено звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | Барлык вазифалар | 49,0 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы» һөнәри квалификация төркеме | Барлык вазифалар | 49,0» |

Бишенче абзацта 8 нче пунктның VIII бүлегендә «10» санын «20» санына үзгәртергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы З.Г. Михайлова

А. И. Хәбиров
5-49-40